**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№М272**
**12.07.2021**

Шәһәр Хакименең 2016 елның 24 мартындагы М 98 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре реестрларын алып бару турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 12 февралендәге ПУ-132 номерлы Указы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Мниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең 2016 елның 24 мартындагы М 98 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре реестрларын алып бару турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктта:

- 1 пунктта «атасының исеме» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

- 15 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«15) хезмәт шартнамәсе яки хезмәт контракты турында (төре, төзү датасы, аның гамәлдә булу срогы, аңа үзгәрешләр кертү датасы).»;

2) 9 пунктта «, шулай ук кәгазьдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 12 пунктта «ике көн» сүзләрен «ике эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

4) 14 пунктта «ике көн» сүзләрен «ике эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

5) 17 һәм 18 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

6) 19 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«19. Муниципаль хезмәткәрләр реестрлары һәм аларга карата үзгәрешләр аларда булган мәгълүматны рөхсәтсез файдалану, юкка чыгару, модификацияләү, блокировкалау, күчермәсен ясау, бирү, тарату, шулай ук башка законсыз гамәлләрдән саклауны тәэмин итеп, Мәгълүмат системасында саклана.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 12 февраленнән башлап барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка, Контроль-хисап палатасы рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев